# *Самигуллина Зәйфәр Кәрим кызы*

*Мин, Самигуллина Зәйфәр Кәрим кызы, 1937 нче елның 19 нчы мартында Татар Алатында туып үстем. Сугышка әтиемнең абыйсы китә һәм кире әйләнеп кайтмый. Әти Мәскәүдә эшләгән чакта, бер күзе сукрая. Шул сәбәпле, сугыштан кала. Әти кораллар ясау өчен, акча белән ярдәм итә алганча булышты. Сугышка бармый калгач, авылдагы тол хатыннарга ярдәм кулын сузды. Без гаиләдә 5 бала үстек. 1941 елны сеңлем Сания туды. Менә шуннан соң сугыш башланды. Ашарга - эчәргә юк, киемннәр юк. Әнинең бәрәңге пешергәнен бик көтә идек инде. Ул чакта күкәрин, кузгалак, кычыткан ашый идек. Шуның белән исән калдык та инде. Бик авыр булса да, әниләргә булыштык, урак өстенә йөрдек, утын ташыдык. Сугышка китүчеләргә, оекбашлар, бияләйләр бәйләп җибәрә идек.*




*Мин 4 класс белем алдым. Бик әз укыдым, ул чакта күп булгандыр инде ул. 4 класстан соң урманга җибәрәләр дип, фермада ат карадым, аннан соң 5 ел сыер саудым. Бик авыр еллар иде шул. 18 ел колхозда, 15 ел пекарняда пешекче булып эшләдем. Шуннан соң, лаеклы ялга чыктым. 38 еллык хезмәт стажым, "Хезмәт ветераны" таныклыгым һәм мактау кәгазьләрем бар. Сугыш беткәнен әле дә хәтерлим. Миңа ул вакытта 17 яшь, Дөбьязга барып куна идек, 1 ипи алыр өчен кичтән барып ,чират торып йокладык. Шул ипине күтәреп алып кайтып килгәндә, сугыш бетте дип безгә әйткәч, ипине йомарлап тотып, туйганчы ашадык. Сугыш вакытында бер капмыйча, әтигә алып кайтып бирә торган идек ипине.*

*1960 елда Юваска килен булып төштем. Биш бала үстердек. Бүгенге көндә Ювaста, улым Мәхмүт, киленеп Чулпан һәм тормыш иптәшем Мансур белән 53 ел гомер итәм.*

*Хәзерге яшь ләргә бәхет, шатлык, куанычлар гына телим. Әти – әниләрен тыңласыннар. Сугышлар булмасын, еллар тыныч булсын. Тату гомер итсеннәр.*